СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2019 г.Зеленодольск № 465

2006 елның 1 февралендәге 36 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 24 мартындагы 58 номерлы, 2007 елның 9 июлендәге 195 номерлы, 2008 елның 29 апрелендәге 295 номерлы, 2010 елның 26 февралендәге 508 номерлы, 2010 елнын 20 декабрендәге 25 номерлы, 2012 елның 20 апрелендәге 149 номерлы, 2012 елның 2 июлендәге 156 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 362 номерлы, 2015 елның 22 маендагы 531 номерлы, 2015 елның 20 августындагы 560 номерлы, 2018 елның 30 маендагы 306 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләре һәм өстәмәләр белән)

Зеленодольск муниципаль районы Советы сессияләрен уздыруны җайга салуда хокукый бушлыкны бетерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль район Советы **карар итте**:

1. 2006 елның 1 февралендәге 36 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламентына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 24 мартындагы 58 номерлы, 2007 елның 9 июлендәге 195 номерлы, 2008 елның 29 апрелендәге 295 номерлы, 2010 елның 26 февралендәге 508 номерлы, 2010 елның 20 декабрендәге 25 номерлы, 2012 елның 20 апрелендәге 149 номерлы, 2012 елның 2 июлендәге 156 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 362 номерлы, 2015 елның 22 маендагы 531 номерлы, 2015 елның 20 августындагы 560 номерлы, 2018 елның 30 маендагы 306 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләре һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1.33 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Советының ачык утырышларында гражданнар (физик затлар), дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.»;

1.2. 33 статьяның 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Советының ачык утырышларында катнашкан гражданнар (физик затлар), дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм чакырылган затлар Район Советы эшенә кысылырга хокуксыз, хуплау яки хупламау чагылышларыннан тыелырга, тәртип сакларга һәм рәислек итүче күрсәтмәләренә буйсынырга тиеш.»;

1.3. 35 статьяның 2 пунктындагы 1 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Район Советы һәм Шәһәр Советының уртак сессияләрен уздырганда беренче булып Район Советы рәисе сессиясен ачып җибәрә, икенче булып Шәһәр Советы рәисе сессиясен ача.

Район Советы һәм Шәһәр Советының уртак сессияләрен үткәргәндә, беренче булып Район Советы рәисе сессиясен яба, икенче булып Шәһәр Советы рәисе сессиясен яба.»;

1.4. 39 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Район Советының һәм Зеленодольск шәһәре Советының уртак сессияләрен үткәргәндә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Гимналары Район Советы рәисе һәм Шәһәр Советы рәисе сессиясен ачу турында игълан ителгәннән соң бер тапкыр башкарыла.

Район Советының һәм Зеленодольск шәһәре Советының уртак сессияләрен үткәргәндә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Гимналары Район Советы рәисе һәм Шәһәр Советы рәисе сессиясен ябу турында игълан ителгәннән соң бер тапкыр башкарыла.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**башлыгы урынбасары** **Э.Р. Кадникова**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ